2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авылы җирлеге Нагорное авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

23 ноября 2024 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлегенең Нагорное авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлегенең Нагорное авылы, Үзәк урам, 17 нче авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (хатыны, йә бер ата-анасы); Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан; уку урыны буенча вакытлыча теркәлүгә ия студентлардан; 1,2 төркем инвалид гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: су белән тәэмин итү системасын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итә торган башка инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау; торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр юл үткәргечләрен һәм күперләрне ремонтлау (коелар төзекләндереп сүүткәргеч линиясен капиталь ремонтлау, каптажны ремонтлау, каптаж өчен киртәләр, санитар-яклау зонасын киртәләү буенча эшләр башкару)?”.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Нагорное авылы, Үзәк урам, 17 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кичү авыл җирлеге башлыгы Г.П.Туманова